**КАРАР**
**Татарстан Республикасының Азнакай район Советы**

Азнакай шәһәре №311-41 «12» декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2013 елның 5 февралендәге 216-32 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче затлар һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында»гы карары белән расланган Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә килүче затлар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 нче маддәсе нигезендә, Азнакай шәһәр прокуратурасының 2019 елның 29 ноябрендәге 02-01-19/1519-8-2019 номерлы «Ачыкланган коррупциоген факторны бетерү максатыннан норматив хокукый актны үзгәртү турында»гы таләбен исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2013 елның 5 февралендәге 216-32 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче затлар һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында»гы карары белән расланган Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә килүче затлар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 пунктта «аерым очракларда», «яки гамәлгә куючы тарафыннан мондый вәкаләтләр бирелгән затлар сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 11 пунктта «срок» сүзен «срокка»дип алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakayevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин